МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ

ДИНОЗАВРЛАР ӨНЕНДӘ



ДИНОЗАВРЛАР ӨНЕНДӘ

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ

ДИНОЗАВРЛАР ӨЕНДӘ

Фантастик повесть

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1978

С(Тат)2
Х91

Мәктәп укучылары Марсия белән Камил урманда бер чокырга юлыгып упкынга очып төшәләр, җир асты елгасы буенча агып китәләр. Повестьта аларның маҗаралы да һәм бик куркыныч та булган сәяхәтләре тасвир ителә.

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Х $\frac{70803-155}{М132(03)-78}$ без объявл.—78

© Татарстан китап нәшрияты, 1978.

БЕЗ ПОХОДТА

Без походта. Без дигәнем — Таулы нефтьчеләр поселогының VI «Б» классы укучылары.

Менә, күрдегезме, сүз башында ук ялгыштым. Алтынчы түгел, хәзер инде без VII «Б» классы укучылары. Бу походка да яхшы өлгереш белән җиденчегә күчкән өчен чыктык.

Тик менә Җәмитнең генә ике «3»лесе булды. Булышмадык түгел, булыштык. Аның ул «өч»леләрен бетерү өчен кыш буе иза чиктек. Ниләр генә эшләп карамадык! Иң каты җәза дип, хәтта классыбызның хоккей командасында уйнаудан мәхрүм иткән идек. Әмма VI «А»га оттыру белән, үзебезгә үк ялынып-ялварып чакырып алырга туры килде. Чөнки аның кебек капкачы бөтен мәктәптә юк. Тикмәгә генә «Третьяк» дип йөртмибез үзен.

Хәер, безнең командада үз Михайловларыбыз, үз Харламовларыбыз, хәтта үз Абрахамссоннарыбыз да бар.

Менә без походта. Мират абыйның әйтүенә караганда, беренче көнне үк утыз километр чамасы юл үттек. Мират абый белән дә таныштырып куйыйм, безнең класс җитәкчесе ул. Ботаникадан укыта.

Яшерен-батырын түгел, Мират абый утыз гына километр дигәч, күңелемдә шик сыман нәрсә туды. Айһай, алай гына үттекме икән? Миңа калса, без күбрәк үткәнбездер кебек тоела. Җилкәдәге рюкзак һаман

авырая бара, каешлары җилкәмне кисеп, тәмам чиләндереп бетерде бугай инде.

Шулай да сер бирү юк. Кая ул! Югыйсә отрядтагы кызлар: «Их сине!» — дип, күзеңне ачырмаслар. Өстәвенә, янымнан гына Марсия атлап бара...

Минемчә, класста иң чибәр кыз ул. Валентина Терешкова исемендәге яшь астронавтлар түгәрәгенә йөргәнгәме, классташыбыз Хәлил Габдуллин аны «Марсианка» дип атады.

Юк инде, дустым Хәлилнең исемен телгә алганмын икән, аның турында бер-ике авыз сүз әйтми булмый. Чөнки, минем әбиемчә әйтсәк, Хәлил кебек укымышлы, аның кебек күпне белгән кеше юк безнең класста. Аннары безнең беребездә дә аныкы кебек китапханә юк. Майн Рид, Вальтер Скотт, Герберт Уэллс, Стивенсон әсәрләре дисеңме, барысы да бар аңарда. Жюль Верн, Фенимор Купер, Дюма, Конан Дойль кебек язучыларны әйтәсе дә юк. Ул аларның әсәрләрен генә түгел, тормышларында булган кызыклы вакыйгаларга кадәр белә. Имештер, Конан Дойль шулай каяндыр кайтып килә икән. Күрә: бер хәерче табаны төшеп калган башмагын караштырып утыра. Бу моның янына килгән дә: «Сэр, бәлки минем башмакларымны киярсез?..» дип, юл читендә утырган әлеге фәкыйрьгә башмакларын салып биреп, яланаяк китеп барган ди.

Хәлилне кемдер, күп белгәне өчен, шаяртып «Габдел ибне Әл-Хәлил» дип атаган иде. Бу исем безгә дә ошады.

Бөтен мәктәп буенча уздырыла торган КВН уеннарында барлык җиңүләрне дә безгә Хәлил китерде дисәм, әллә ни зур ялгышлык булмас. Без хәтта җиденче, сигезенче класслар белән дә көч сынашып карадык. Әле дә булса хәтеремдә, VIII «А» классы белән КВН үткәргәндә Хәлил искәртмәстән генә: «Дөньяда җәядән иң оста һәм иң ерак атучы кем?» — дип сорап куймасынмы. Тегеләр ык-мык иттеләр, илебез чемпионнарының, хәтта олимпия уеннарында җиңүчеләрнең исемнәрен атап карадылар. Ләкин дөрес җавап бирә алмадылар. Соңыннан инде үзеннән әйттерделәр. 1761—1808 елларда яшәгән, төрек солтаны Сәлим III булган икән. Аның җәядән төзәп җибәргән угы 889 метрга очкан. Хәлил, сүзен исбат итү өчен, «Чехословакия» дигән

журналны күрсәтте. Шундый ул — безнең классның акыл иясе Габдел ибне Әл-Хәлил!

...Менә без, кыр казлары кебек тезелешеп, һаман атлыйбыз да атлыйбыз. Ничек арганымны бер үзем генә беләм. Мин түгел, әнә, безнең белән сәяхәткә чыккан Актүш тә тәмам әлсерәде. Гап-гади лайка ул. Шулай да яратабыз үзен. Ни әйтсәң дә, космоска иң беренчеләрдән булып юл салучылар токымыннан бит.

Мират абыйның:

— Привал!..— дигән командасы яңгыраганда, кояш баю ягына авышкан иде инде.

Уф-ф!.. Бу минутларны да күрер көн бар икән. Ниһаять, көне буе җилкәбездә биегән биштәрләрдән котылдык. Биштәре биштәр генәме соң аның! Азык-төлек, савыт-саба, җылы киемнәр дисеңме... шуның өстенә әле кайсыдыр: «Син, Камил, булачак геолог»,— дигән булып теленә салынып, ансыз да тау кадәрле рюкзак янына палатка да китереп асты. Болардан тыш, билдә — махсус футлярга салынган тимер саплы поход балтасы.

Безнең арганны Мират абый да сизенгән икән:

— Беренче көнне, ияләшкәнче, шулай авыррак булыр инде ул,— дип юаткан була.

Әйтерсең лә кемдер зарланган!

Туктаган урыныбыз шәп иде. Ярларын куе камышлыклар бизәгән шактый зур күл буе. Арабызда балыкчылар да бар. Кайберләре хәтта кармак таякларына кадәр алганнар. Тик ник берсе «балык» дип авыз ачсын! Кичке аштан соң ук, палаткаларга таралышып, йокларга яттык.

БӘЛА АЯК АСТЫНДА

Таң белән торып, тамакларны ялгап алгандай иттек тә яңадан юлга чыктык.

Биштәрләребез яңадан җилкәгә менеп кунаклады. Кичәге әйберләрем янына кемдер тагын ут өстендә ысланып беткән, корымнары да рәтләп сөртелмәгән чиләк асып куйды. Минем җилкәм калын янәсе!

Як-ягыбызда офыкларга барып тоташкан тигезлек. Кояш кыздыра. Эчәсе килә. Якын-тирәдә су-фәлән күренми. Түзәсең, башка чараң юк.

Чамасыз кыздырган кояш баш очыбызга күтәрелеп җиткәндә, ниһаять, алдыбызда урман күренде.

Бераздан текә яр астыннан ургылып торган боздай салкын чишмә янына барып чыктык. Иң элек туйганчы, тешләребез камашканчы су эчтек, аннары рәхәтләнеп юындык. Кайберәүләр хәтта, биштәрләрен салып атып, сузылып ук яттылар.

Мират абыйның әмер-боерыгы кыска:

— Кузгалдык!

Менә урман башланды. Аның куе күләгәсенә барып кергәч, тәннәр рәхәтләнеп китте.

— Укучылар!..— диде Мират абый, барыбызга да берьюлы мөрәҗәгать итеп.— Әллә ни ерак китмәгез, таралышмагыз. Шулай ук эшегез бар икәнлекне дә онытмагыз...

Походка чыгар алдыннан гына төрле түгәрәкләр оештырылган иде. «Эш» дип шуны әйтә инде Мират абый.

— Гербарий җыючылар өчен бер белдерү. Шушы көннәрдә генә «Неделя»да бик кызыклы бер хәбәр укыдым. Ерак Көнчыгыш тайгасында гына үсә дип саналган, халык теленә «тереклек тамыры» дип кергән женьшеньны Ленинград өлкәсендә дә тапканнар...

Бу чыннан да яңалык иде. Укучылар үзара шаулашып алдылар.

— Нинди була икән соң ул женьшень?..

— Чыннан да...

— Таба-нитә калсак, ничек танырбыз соң без аны?

— Күргән-белгән нәрсә түгел...

— Әйе шул.

Мират абый тыныч кына:

— Ә сез болай итегез, ят үлән тапсагыз мине чакырыгыз,— диде.

Урман шәп. Балта-пычкы тимәгәнгә охшый. Урыны белән кеше аягы басмаган куелыклар, ерып үтә алмаслык чытырманлыклар да очраштыргалый. Ачыграк урыннарда бил тиңентен куе үлән үскән. Ә аланлыкларда мең төрле чәчкә. Хуш ис. Агач төпләрендә, үлән әллә ни котырып үсмәгән урыннарда, уттай янып, каен җиләкләре җемелдиләр.

Төрлебез төрле якка таралышып беттек. Һәркем үз эше белән мәшгуль. Ә мин җиләк чүплим. Мине женьшень кызыксындырмый. Минем хобби — минераллар. Геолог-минеролог булырга хыялланам мин. Инде хәзер дә теләсә кем кызыгырлык коллекциям бар. Бу эштә миңа иптәшләрем генә түгел, хәтта эти дә ярдәм итә. Ул бораулаучы булып эшли. Миндә девонга кадәр булган барлык тау-таш токымнарының да үрнәкләре бар. Малахит, лазурит, якут, ахак турында әйткән дә юк. Миндә хәтта Уралның табигый асылташларыннан топаз, аметист кебек сирәк ташлар да бар. Аларны әниемнең Свердловск шәһәрендә яшәүче туганнан туган абыйсы җибәрде. Әл-Хәлилнең әйтүенә караганда, минем коллекциядә хәзер бары тик «Армолколит» * дип атала торган ай токымы гына җитми икән. Беркөн генә Хәлил үзе үк мине шаккатырырлык яңалык алып килгән. «Армолколит» минералын җирдән, көньяк Африканың алмаз шахталарыннан табып алганнар. Менә сиңа мә!.. Җир белән Ай «бертуганнар» икән ләбаса.

Куе үлән арасыннан искәрмәстән генә атылып килеп чыккан Актүш уйларымны бүлдерде. Ул арада «А-ууу!» дип кычкырып барыбызны да зур аланлыкка чакыра башладылар. «Табигать һәм фантазия» түгәрәге членнары үзләре тапкан нәрсәләрне күрсәтергә теләгәннәр икән. Ауган агачның юан кәүсәсе өстендә күргәзмә кебек нәрсә дә ачып җибәргәннәр.

Менә нәни йодрык кадәрле генә мүк кисәге. Мүк өстендә кызарып пешкән ике-өч бөртек җир җиләге. Аңа чак кына хыялга бирелеп карасаң, хәйран каласың. Мүк кисәге түгел, ә инәләренә алмалар кадап каядыр китеп баручы керпе икән ләбаса! Әнә — башы, әнә — тәпиләре, хәтта очлы борыны белән елтыр күзләренә кадәр бар.

Шунда ук, як-якка очлы чыбыкларын тырпайтып, бер ботак кисәге басып тора. Монысының Тукай әкияттеннән килгән Шүрәле икәнлеген тануы әллә ни кыен түгел. Өч җәпле чыбык та гади чыбык түгел, ә бик күп әкиятләрдә очрый торган өч башлы аждаһа...

---

[1] «Армолколит»— минералны беренче булып Җиргә алып кайткан «Аполлон-11» экипажы астронавтлары Н. Армстронг, Э. Олдрин һәм М. Коллинз фамилияләренең беренче иҗекләреннән ясалган исем.

Күргәзмәне бераз тамаша кылгач, яңадан кайсыбыз кая таралышып беттек. Мин дә, куе урманның бер ягында үзәнлек сыман урын барлыгын абайлап, шул якка таба юнәлдем. Берәр ишелгән яр яки чокыр очрамасмы? Кемгә нәрсә, ә миңа минерал кирәк. Өйдәге китап киштәләрен, шкаф өсләрен минераллар белән тутырып бетергәнгәме, әби еш кына миннән: «Тиле таш җыяр»,— дип көлә.

Шул вакыт якында гына, чокыр сыман уйсулык ягыннан, кемнеңдер:

— Кот-ка-ары-гыз!.. А-а-а!..— дип, ярдәмгә чакырган тавышы ишетелде.

Чәч төпләрем чымырдап китте. Мөгаен, берәрсен елан чаккан! Тукта, Марсия тавышы түгелме соң?

Тавыш килгән якка ташландым. Куе куаклыклар арасыннан, ваграк агачлар астыннан иелә-иелә узам. Кыңгырау кебек чыңлап торган тавышы белән өрә-өрә, янымнан Актүш тә чабып үтте.

Йөгереп килеп җитсәм, куе үлән белән капланган чокыр төбендә — Марсия. Ул хәлсез кулы белән агач тамырына чак-чак кына ябышып тора иде.

— Тиз бул!.. Тиз...

— Хәзер, Марсия... Хәзер!..

Ике атлап, бер сикерү белән Марсия янына очып төштем. Уң кулым белән чокыр өстенә үк иелеп үскән агачның аскы ботагына ябыштым да сул кулымны Марсиягә суздым.

— Ныграк тотын, яме...

— Я-яра-ар...

— Тотындыңмы?..

— Әй-йе...

Әллә инде каушап калдым, һич кенә дә өстерәп чыгарыр хәл юк. Аякны терәп басарлык та түгел бит, ичмаса. Ә артымда, ярдәм итәргә теләгән сыман, чинап-шыңшып, Актүш чуала.

— Тарт инде!..

Марсиянең тавышы ничектер калтыранып, өзгәләнеп чыкты.

— Төпсез чокыр... монда...

— Хәзер, була...

«Әллә иптәшләрне ярдәмгә чакырыргамы икән?» — дигән уй чагылып китте башымда. Әмма Марсиянең:

«Әллә егет башың белән мине дә тартып чыгарырлык көчең юкмы?!» дип уйлавыннан курыктым.

Шул чак бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Мин көчкә-көчкә генә аягымны терәп торган чокыр авызы кинәт йомшарып китте. Ул да түгел, убылып ишелә дә башлады. Мин, тез буыннарым калтырап, бер якка аудым. Егылганда, ничектер Актүшне төртеп җибәргәнмен. Ул чинап-елап тонык кына гөрелте ишетелеп торган упкынга төшеп китте дә тынсыз булды.

Хәлебез яман. Хәзер инде мин дә яртылаш асылынып торам. Шулай да, иптәшләрне ярдәмгә чакыру нияте белән, башымны артка таба чөя төштем. Шунда бөтен тәнем эсселе-суыклы булып китте. Агарып калган кулым әлеге тотынып торган ботак кәүсәсеннән аерылып бара иде. Мин ирексездән кычкыра башладым:

— Әй-й-й!.. Ярдәм итегез!..

Кемнеңдер: «А-у-у!.. Сез кай-да-а?..» — дигән тавышларын ишеткәндәй булдым. Калкулыктан безгә таба йөгерешеп килүче иптәшләрне дә күреп алдым. Ләкин мин тотынып торган ботак хәзер инде каерылып ук чыккан иде. Без Марсия белән бер-беребезгә тотынышып караңгы, упкын төбенә төшеп киттек...

МӘҢГЕЛЕК КАРАҢГЫЛЫК ЭЧЕНДӘ

Барысы да күз ачып йомганчы булды.

Иң элек, ниндидер бушлыктан очып үтеп, сап-салкын агым суга барып төштек. Аңыбызга да килергә өлгермәдек, ул безне үзенә ияртеп, яңадан каядыр агызып алып китте...

Аяк-кул тышауланган кебек. Марсия чытырдап миңа ябышкан. Рюкзагы юешләнеп, күтәрә алмаслык хәлгә килгән. Бетүебез шушы икән...

Су агымы бераз кими төште. Ләкин күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Каяндыр, югарыдан кебек, шарлавык аккан тавыш ишетелә.

Шул вакыт аяк астында каты җир тойган сыман булдым. Чыннан да, су төбе ич...

— Марсия!.. Марсия дим... Аягыңа бас. Монда сай...

Әллә инде ишетмәде. Бәлки, куркудан һушын югалткандыр. Ә үзе һаман әле миңа чытырдап ябышкан килеш тора.

— Марсия дим...

Ниһаять, ул аңына килде.

— Ә?..

— Аягыңа бас дим... Сай монда.

Шунда шарлавык гөрелтесе аша эт өргән тавыш ишетелгәндәй булды.

— Чү-ү!..— дидем мин.— Актүш түгелме соң?..

Өрү тавышы яңадан кабатланды.

— Шул!..— диде Марсия, калтыранып.

Мин шатлыгымнан кычкырып җибәрдем.

— Актүш!.. Актүш!.. Син кайда?..

«Мин монда» дигән сыман итеп, аның чинау катыш өргән тавышы кабат яңгырады. Бу тавыш уң яктарак шәйләнә иде.

Без саклык белән генә шул якка таба киттек. Су саекканнан саега бара. Бераздан аяк астыбызда ташлар да, агач ботаклары да очраштыргалый башлады. Актүшнең өрүе дә якында гына. Тагын берничә адым ара үткәннән соң, мин инде аның яшел ут кебек янып торган күзләрен дә күреп алдым.

Корыга чыктык. Ниндидер эре-эре ташлар арасыннан барабыз. Актүш елап-чинап безгә ташланды. Куануының чиге-чамасы юк. Үзен бу шомлы караңгылыктан коткарырга төшкәннәр дип уйлагандыр инде, мескенкәй.

Марсиянең гәүдәсе дерелдәп-дерелдәп куя. Ул мышык-мышык елый иде. Минем дә бугазыма ниндидер төер кереп утырды. Кая эләктек без? Нинди урын бу? Алда безне ни көтә?.. Әллә мин дә елыйм инде? Юк, тизрәк Марсияне юату ягын карарга кирәк.

— Марсия... Син нәрсә?.. Курыкма...— дидем мин, тавышымның калтырап чыгуын үзем үк тоеп.— Курыкма... Бер дә куркыр нәрсә юк. Безне монда калдырмаслар. Ярдәм итәрләр...

— Итәрләр!.. Ничек итеп?..— дип, кырт кына әйтеп куйды Марсия.

— Ничек дип... Ничек булса да,— дидем мин, кулларым белән як-ягымны капшаштырып. Үзем һаман да Марсияне тынычландырырга, өметләндерергә тырышам.— Безнең бит... чокырга төшеп киткәнебезне күреп калдылар...

Марсия тагын әрнүле тавыш белән сорап куйды:

— Кем күрде? Я, әйт, кем күрде?..

— Малайлар күрде. Кызлар да... Без төшкән чокырга таба йөгерәләр иде бит.

Һәрхәлдә, бу минутта мин үз сүзләремнең дөрес булуын үлеп-үлеп тели идем. Чыннан да, күрделәрме икән соң? Хәер, күрмәгән хәлдә дә безнең юклыкны өстә бик тиз абайлап алырлар, эзләү чарасына керешерләр.

Марсия һаман елый. Үзе дер-дер калтырый. Моны мин аның беләгемә тотынып торган кулларыннан тоям. Минем дә үз хәлем хәл. Аягымда чак-чак басып торам.

Кинәт шунда кесә фонарем барлыгы исемә төште.

— Карале, минем фонарь бар бит!..— дидем мин, куанычлы хәбәр әйткән сыман итеп.

Ләкин күңелем шундук сүрелеп китте. Ярый ла, аңа дым үтмәгән булса.

Җәһәт кенә җилкәмдәге биштәрне салдым. Доңгылдап чиләк бәрелгән, шаулап су түгелгән тавыш ишетелде. Әйтәм, биштәрем тимер тутырылган сыман авыр иде, чиләккә су тулган булган икән.

Иелеп биштәр авызын чишә башладым. Янымда ук тезләремә елышып, шыңшып-елап Актүш бөтерелә. Кулым җебеп тәмам эштән чыккан ипиләргә, азык-төлеккә барып төртелде. Йөрәгем жу итеп китте. Безнең бит әле ач калуыбыз да бар икән.

Менә кулым фонарь тимеренә дә тиеп китте. Мин тиз генә фонарьны алып черт иттереп төймәсенә бастым. Кабынмады. Бары тик уч төбемә фонарь эченнән су гына агып чыкты.

— Таптыңмы?..— дип сорап куйды Марсия.

— Таптым. Тик...

— Кабыз инде тапсаң...

— Аның батареясы юешләнгән ахры. Хәзер кабынмыр...

Чыннан да, икенче тапкыр басуым булды, тоныккына саргылт нурлар аяк астыбызны яктыртты. Күңелләргә җан керде. Баш очыбызда кинәт йолдыз кабындымыни! Өмет йолдызы...

— Сал биштәреңне,— дидем Марсиягә һәм үзем үк салырга ярдәм иттем.

Бары тик шуннан соң гына, тирә-юнебезне фонарь уты белән яктыртып, үзебезнең кайдалыкны күзәтә башладык. Як-ягыбызда төбе-тамыры белән йолкынган, шунлыктан әллә нинди кыяфәтләргә кергән агач-

лар. Кайберләре, агач булудан бигрәк, эре җанвар сөякләрен хәтерләтәләр. Арада без география дәресендә узган Африка саванналарындагы баобаб агачы кәүсәләренә охшаганнары, шактый юаннары да бар. Каян килгән алар монда? Кайчан да булса, каян да булса убылып-ишелеп төшеп, агып килгән булырга тиеш, мөгаен.

Яктылыкны мәгарәнең түшәменә юнәлттем. Анда, менә-менә ычкынабыз дигән сыман, эре-эре ташлар асылынып тора. Үзләре ташкүмергә охшап, салкын яктылык сибеп ялтырыйлар. Әй-йе, дип уйлап куйдым мин. Әби әйтмешли, җәһәннәмнең нәкъ үзәгедер бу...

Бар курыкканым, бу хәлләрне күреп, өне алынган Марсиянең яңадан елый башлавы иде. Марсия, Марсия! Галәм һәм йолдызлар дип саташкан классташымның хәзерге халәтен аңлавы әллә ни кыен түгел иде.

— Ут ягарга кирәк...— дидем, уй-фикерләрне читкә юнәлтергә теләп. Һәм шундук: — Ә шырпы? — дип уйлап куйдым.— Ул да юешләнеп беткән булса?..

Хәер, таш бар, агач та — күпме кирәк, утны борынгы ысул белән табарга мөмкин. Фонаремны яныбызда яткан юан агачның кәүсәсенә куйдым да яңадан рюкзагыма иелдем. Шырпы, запас батарей, лампочкалар, тагын шундый вак-төяк тутырылган целлофан капчыкны эзләп таптым. Әйе, шырпы чыннан да чыланган. Әмма кабы таралмаган, ә шырпыларның күкертле башлары исән.

Үземнең сер бирү юк:

— Хәзер, киптерәбез аларны...— дигән булам.

Иң элек, шырпыларны чыгарып, саклык белән генә, фонарь янына тезеп салдым. Ә Актүш, башын кырын куеп, минем һәрбер хәрәкәтемне күзәтеп тора.

Менә балта кайчан кирәк булды! Аны футлярыннан чыгардым да фонарь яктысында коры-сары хәзерли башладым. Аннары шырпыларны тизрәк киптерү чарасын күрдем... Ике утын агачы алып, чак кына шомарткандай иттем дә, бер-берсенә аркылы куеп, җанфәрманга ышкый башладым. Күпмедер вакыт ышкыганнан соң, шырпылар белән шырпы кабын утын агачларының ут кебек булып кызган урынына тезеп салдым. Ә үзем, шарт та шорт суккалап, ягар өчен агач

хәзерлим. Балта авазы, бөтен мәгарә эчен тутырып, әллә кайларга ишетелә.

Учакны кабызып җибәрүе әллә ни кыен булмады. Беренче шырпы ук гөлт итеп тирә-якка яктылык чәчте.

Ә инде учак кызып, эрерәк агачларны да ялкын алгач, тирә-як кинәт киңәеп тә, ачылып та китте. Мәңгелек караңгылык безнең тирәдән каядыр читкәрәк чигенгәндәй булды.

АЗЫК-ТӨЛЕКНЕ БАРЛЫЙБЫЗ

— Иң элек ипи белән азык-төлекне барлыйк,— дидем мин. Һәм шундук әйткән сүзләрем өчен үкенеп бетә алмадым. Ач калу турындагы уй Марсияне куркытмасмы соң?..

Ачык океанда 49 көн буена интеккән Әсгать Җиһаншиннар исемә төште. Алар бит күн итек кунычларына кадәр ашап бетергәннәр. Бу турыда Марсия да бик яхшы белә. Чөнки, өченчеме, дүртенчеме класста укыганда, «Алар дүртәү иде» дигән повесть буенча укучылар конференциясе уздырган идек.

Минем биштәрдә ике бөтен ярым ипи бар. Алар шул кадәр җебегән, таралып китмәсеннәр өчен, саклык белән генә чыгарып, ут янындагы яссы таш өстенә куйдым. Ипи исен сизгән Актүш, койрыгын болгый-болгый, ашарга сорап шыңшый ук башлады. Капчыкта уалып калган ипи валчыкларын сыпырып җыеп алдым да читтәрәк яткан таш өстенә салдым. Маэмай бер генә ялманды, таш өсте ялт итте.

Минем биштәрдә тагын целлофан капчыкка тутырылган макарон, шундый ук капчыкка салынган тоз, җебеп тарала башлаган бер пачка шикәр бар иде. Аз булса да ысланган колбаса да килеп чыкты. Шундук капрон тартмада чәй, уха пешерергә дип алган кара борыч, лавр яфраклары... Капчык төбендә тагын унбер бәрәңге, ике баш суган. Менә бар булган нәрсә шул.

Бәхеткә каршы, Марсия капчыгы да буш түгел иде. Аннан да бер ипи, җебегән булса да бер батон, өч банка ит консервысы, дүрт пачка карабодай концентраты, өсте капрон белән яхшылап ябылган бер банка май, берничә конфет (кызларның шул булыр инде) һәм бер-

берсенә ябышып, тәмам укмашып беткән икеме-өчме прәннек чыкты. Аларның һәркайсын һәйбәтләп ут янына тезә бардык.

Таш өстенә тезеп куйган әйберләребезнең әле бер ягын, әле икенче ягын утка таба каратып боргалап торабыз. Ипиләрне дә киптердек. Болардан бөтенләй сохари ясарга туры килмәгәе әле...

Ул арада башка әйберләребезне, кием-салымнарны да караштырырга кирәк иде. Биштәргә тагылган палатканы таратып ташладым. Аннары инде рюкзактан кедаларны чыгардым. (Аягымда ботинка.) Тагын бер күлмәк тыгылган. Бер аш савыты, кружка. Пычаклы, чәнечкеле һәм кашыклы бер пәке. Шуның өстенә әле тагын кемнеңдер кашыгы адашып минем капчыкка эләккән. «Актүшкә булыр...» — дип көлеп куйдым мин.

Өстемдә күлмәк. Пинжәк. Чалбар. Ә баштагы кәпәч югалган.

Марсиянең дә, өстендәге күлмәгеннән тыш, җылы свитеры, сөлгесе, сабыны, теш пастасы, щеткасы бар. Аннары инде савыт белән кашыгы. Кружкасы...

Берьюлы кием-салымнарыбызны да киптерергә булдык. Мин колга сыман озын агачлар табып, аларның ботакларын сындыргаладым да, бер башын яныбызда яткан юан агач кәүсәсенең өскә таба тырпаеп торган тамырына, икенче башын зур гына таш өстенә куйдым. Иң элек палатканы элдем. Аннары пинжәгем белән күлмәкне. Марсиянең свитеры белән күлмәгенә дә урын табылды. Ә майка белән оекларымны утка якын торган эрерәк ташлар өстенә җәеп-таратып салдым.

Мәгарә эче коры, җылы. Бары тик шарлап аккан су ягыннан гына салкынлык бөркелеп тора.

— Марсия...— дидем мин, һаман да әле аңына килә алмыйча ут янында бөрешеп утырган классташыма.— Әллә капкалап алабызмы?

Җавабы кыска:

— Юк. Ашыйсы килми.

— Ашамыйча ярамас...

— Үзеңә кара. Мин теләмим...

Инде нишләп карарга?

— Алайса чәй кайнатам...— дидем мин, урынымнан сикереп торып.— Ә суы... эчәргә ярыймы икән соң?

Калкып чыгып торган эрерәк ташлар өстенә басып, чиләкне мөлдерәмә итеп тутырып алдым. Ут янына

килгәч күрдем: су көмештәй чиста. Тәме дә чишмәнеке кебек.

Искәрмәстән генә Марсиянең үксеп-үксеп елый башлавыннан чәчрәп киттем. «Нәрсә булды?..»— дип янына ташландым. Ә ул елавын белә. Менә бит, ә! Хәзер инде нишләргә?

— Син елама әле, Марсия...— дидем мин, аны юатырга теләп.— Менә күрерсең, тиздән безне коткарачаклар...

Марсиянең үз туксаны туксан.

— Ничек итеп?.. Йә әйт, ничек итеп?..

— Ничек итепме?.. Бик беләсең килсә, ишет алайса. Иң элек... Иң элек безнең югалуыбыз турында... Ну, чокырга төшеп китүебез турында тиешле урынга хәбәр итәчәкләр. Шундук коткару партиясе килеп җитәчәк... Ә алар «гетаскаф» дип атала торган скафандр алалар да безнең янга төшәләр... Хәзер андый гетаскафларны җир астында басылып калганда яки шахталарда ут чыкканда кешеләрне коткару өчен файдаланалар. Бу турыда инде мин, бик беләсең килсә, әллә ничә тапкыр укыдым.

«Тагын нәрсә дияргә, нәрсә дип юатырга инде?» — дип баш ваттым мин.

— Аннары бит безнең бу якларда җир асты елгалары, җир асты куышлыклары барын галимнәр беләләр...

Шунда мин Марсиягә бу турыда бөтен белгәннәремне, ишеткәннәремне тезә башладым. Әлмәт районында җир сөреп йөргәндә, бер тракторны «җир йоткан». Сабаны гына калган. Аннары этиләр бригадасының, скважиналары җир асты куышына туры килү сәбәпле, ай буе авариядә утырулары турында да сөйләдем. Алар, бәладән котылу өчен, машиналар белән ташып, метрлап киселгән юан агачлар, ташлар, тагын әллә нәрсәләр тутырып караганнар. Тик бер нәрсә дә ярдәм итмәгән. Ахыр чиктә Бөгелмәгә, фәнни-тикшеренү институтына хәбәр иткәннәр. Аннан килеп тикшергәннән соң: шаулап елга агып тора торган җир асты куышлыгына эләккәнсез дип, буровойны башка урынга күчерттерделәр.

— Алай гына да түгел,— дип дәвам иттем мин.— Казаннан да килгән булганнар. Төрле приборлар белән җир асты куышының зурлыгын, елгасының агым көчен, тирәнлеген үлчәгәннәр. Аннары инде тамгалы атомнар

җибәреп, вертолетка куелган локатор ярдәмендә, җир асты елгасының кай якка акканын, кая койганын тикшергәннәр...

Шул вакыт Марсиянең җан-фәрманга:

— Ой-й, Ка-ми-ил!..— дип чырылдап кычкырып җибәрүеннән өнем алынды.

Ул да булмады, Актүш тә яман өрә башлады.

Нәрсә булыр, бу?

КӨТЕЛМӘГӘН «КУНАКЛАР»

— Кая?.. Нәрсә бар?..— дидем мин үз тавышымны үзем танымыйча.

— Әнә!.. Әнә ич...

— Кайда?..

— Соң, әнә ич инде! Нәрсәләрдер... очалар.

Нәкъ шул вакытта ниндидер җан иясенең колагым төбеннән генә выжылдап очып үткәнен тоеп калдым. Ул да түгел, бер нәрсәнең гаять зур тизлек белән ут яктысында чагылып үтүен күрдем.

— Ә-ә-й, ярканатлар ич!..— дидем мин, куануымнан нишләргә дә белмичә.— Минем шакылдавым яки учак төтене тынгысызлаган булырга тиеш аларны. Димәк, шушы тирәдә генә җир өстенә чыгу юлы да бар...

Бу чыннан да зур шатлык иде. Шунда ярканатлар, кулканатлар турында зоология дәресендә үткәннәребез искә төште. Аларга яктылыкның һич кенә дә кирәге юк икән. Күзләре капланган ярканатның агач ботакларына, тау-кыяларга кагылмыйча очып йөрүе, шул ук вакытта азыкны да күзләре ачык кошлар шикелле бик оста аулавы ачыкланган. Барысы да ультратавыш дулкыннары хикмәте... Эхолот белән радиолокаторларның төзелешләре дә кулканатлыларның юнәлеш алу органнары принцибына нигезләнгән.

Ярканатлар, ниндидер яман гамәлгә ниятләнгәндәй, тыз-быз килеп очып йөрделәр дә җир асты елгасы ага торган кыялы тау куышына таба очып китеп юк булдылар.

Ул арада чәй кайнап чыкты. Чиләкне читкә алып куеп өстенә бераз чәй бөртекләре койганнан соң Марсиягә тамак ялгап алырга куштым. Әмма ул баш тартты.

— Алайса, Марсия, син ял итеп ал,— дидем мин.

Ул җавап кайтармады. Мин тиз генә ятар урын хәзерли башладым. Агач кәүсәсе буендагы эрерәк ташларны читкәрәк этәреп, яссыракларын тигезләп түшәдем дә, шунда тәмам кибеп өлгергән палатканы җәйдем. Баш очына пинжәгемне салдым. Марсия ятты. Палатканың артып калган киң итәге белән баштанаяк томаланды да тынып калды.

— Тыныч бул, Марсия...— дидем мин, аны кабат юатырга теләп.— Мин дежур торырмын...

Ул дәшмәде.

Актүш тә аның баш очына сузылып ятты. Мин, озаграк янсыннар өчен, утка эрерәк агачлар салдым. Аннары, Марсиянең аяклары очына килеп, палатканың чыгып торган итәгенә утырдым. Бер мәлгә шундый тынлык урнашты, хәтта куркыныч була башлады. Бары тик суның шаулавы гына аермачык булып ишетелеп тора.

Ут яктырак яна башлагач, тирә-яктагы шыксызлык тагын да ачыграк булып күренде. Хәвефле үкергән шарлавык ягына карамаска тырышам. Аның ургылып-шаулап агып төшкән урынында, ниндидер җан ияләре мәрхәмәтсез сугыш алып баргандай, су актарыла, бөтерелә, тирә-якка тик ак күбекләр генә чәчри.

Башымда мең төрле уй. Җитмәсә тагын берсеннән-берсе яманраклар...

Иртәгә үк үзебез агып төшкән шул шарлавык тирәсен җентекләп карарга кирәк булыр. Бу җәһәннәмнән котылу юлы юкмы икән?

Иртәгә... Хәзер көннең нинди сәгатьләре икән соң? Үч иткәндәй, икебезнең беребездә сәгать юк. Иптәшләрдәге биш-алты транзисторның да бездә берсе генә булса икән!

Күзләрен челт-челт китереп ут ягына карап яткан Актүш, кинәт колакларын торгызып, башын калкытты һәм сикереп торып ырылдый башлады.

— Тс-с!.. Шаулама...— дидем мин, Марсиянең уянуын теләмичә. Ә үзем: «Нидер сизенә бу, нәрсә булыр икән?» дип уйлап куйдым.

Шул вакыт, ялкынга тиярдәй булып, баш очыбыздан гына зур ярканат очып үтте. Бу юлы Актүш ырылдап кына калмады: һау-у! дип өреп куйды. Тагын бер ярканат выжылдап очып үтте. Әнә тагын... Тагын. Ут

өстендә шактый кубәйделәр алар, шыксыз зур кара күләгәләре белән мәгарәнең бөтен түшәмен тутырдылар. Баягынак күреп куанган бу көтелмәгән «кунаклар» хәзер күңелгә шом сала башладылар. Ирексездән, быел гына үткән «Зоология» китабында ярканатлар турында әйтелгән сүзләр искә төште. «Африканың тропик урманнарында кан эчүче ярканатлар яши. Төн җиткәч, ярканат ауга чыга һәм пәке кебек үткен тешләре белән хайван тиресен ярып җибәрә дә агып чыккан канын ялый...»

Чыннан да, бу тавыш-тынсыз очып йөргән нәмәстәләр бер дә безнең «Зоокабинет»тагы ярканат карачкысына охшамаганнар: үзләре эре, шуның өстенә әле тагын шактый озын койрыклары да бар. Әллә моннан миллион ел элек яшәгән оча торган кәлтәләрнең берәр төрләреме үзләре?

Ярканатлар ничек тавыш-тынсыз килеп чыксалар, шулай искәрмәстән генә юк та булдылар. Актүш тә, тынычланып, баягы урынына барып ятты.

Учакка утын өстәп, кисәүләрен рәтләп утыра торгач минем дә йоклыйсым килә башлады. Күз кабакларым авырайды, күтәреп торыр хәл юк. Әмма, яхшы беләм, йокларга ярамый. Түзәргә, түзәргә! Бу мәңгелек караңгылык патшалыгында ниләр генә булмас, җиде кат җир асты бит ул. Еланы, чаяны... Тагын шундый агулы әкәм-төкәме. Шуннан мин ирексездән балтамны янымарак алып куйдым. Әнә шулай учак җылысында оеп кына утыра бирәм.

...Каяндыр югарыдан тантаналы марш кебек музыка ишетелгәндәй булды. Музыка көчәйгәннән-көчәя барды. Бераздан аның дәртле авазлары белән бөтен мәгарә эче тулды. Ур-ра-а!.. Безнең кайдалыкны белгәннәр! Безне тапканнар...

Күп тә үтмәде, космонавтлар кебек гетаскафлар киеп алган кешеләр дә күренделәр. Берәү, икәү, өчәү... Алар, узышып уйнаган кебек, шарлавыктан очып кына төштеләр. Кулларында бик якты фонарьлар. Бәлки шуңа күрәдер, әле баягынак кына шыксыз-ямьсез булып күренгән шарлавык тирәсе без «Материклар географиясе»ндә үткән, гүзәллеге белән бөтен дөньяда дан тоткан Виктория шарлавыгына охшап калды. Замбези елгасындагы ул шарлавык тирәсендә һәрвакытта

да бик вак тамчылардан барлыкка килгән салават күпере асылынып тора, диелгән иде китапта.

Ул арада гетаскафлар кигән кешеләр безне дә күреп алдылар. «Менә кайда алар, сәяхәтчеләр!..» дип безнең янга ярга чыктылар. Үзләре белән безгә дип запас гетаскафлар да алып төшкәннәр икән. Тиз булыгыз, киенегез! Өстә сезне дусларыгыз, әти-әниләрегез көтәләр, янәсе. «Ә Актүш?..» дим мин. Берсе көлә: юкка хафаланмагыз, аны да монда калдырмабыз, имеш. Актүшне дә скафандр каскасы сыман үтәдән-үтә күренмәле пыяла шар эченә утырттылар... Бераздан без, нәкъ кармакка эләккән кальмарлар кебек, лебедка тарткан корыч трос ярдәмендә өскә таба күтәрелә дә башладык...

— Камил!.. Камил дим...

Марсиянең еламсыраган тавышыннан сискәнеп уянып киттем. Карасам, без һаман да шул караңгы, шөкәтсез мәгарә эчендә икәнбез әле...

— Нәрсә?..— дидем мин, һаман да әле татлы төшемнән арынып җитә алмыйча.

— Әнә, Актүш... колбасаны ашап бетергән. Бер ипинең дә яртысыннан артыгын юк иткән...

Бу сүзләр мине бик тиз айнытты. Ничек инде шул арада ничаклы әйберне ашап бетерергә мөмкин. Аннары Актүш рөхсәтсез валчык кадәр нәрсәгә дә тими иде бит. Шикле шикләнер дигәндәй, бәлки?..

— Бәлки, ул түгелдер?..— дидем мин, шомланып кына.

— Актүш инде,— диде Марсия чынлап торып ачуланып.— Менә, ипинең калган өлешен авызыннан диярлек алып куйдым.

Бу хәбәр мине әллә нишләтеп җибәрде. Йөрәгем урыныннан купкандай булды. Берсеннән-берсе яманрак, шыксызрак уйлар да озак көттермәделәр...

— Эх-х син, Актүш! Шулай итәргә ярый димени инде!..— дидем мин чынлап торып әрнеп, ачынып.

КӨНМЕ, ТӨНМЕ? БЕЛМИБЕЗ...

Көнме, төнме? Белмибез...

Шактый вакыт үткән булырга тиеш, чөнки үтереп ашыйсы килә башлады. Бәлки шуның галәмәтедер, кыл өзәрлек тә хәл калмаган.

Иң элек ашарга пешереп алырга булдык. Мин чиләк белән су алып килеп, учакка охшатып ике ташны янәшә куйдым да, чиләкне шуның өстенә утырттым. Астына мул итеп утлы күмер, кисәү башларын тартып, яңадан утын өстәдем.

Ул арада Марсия эрерәк өч бәрәңге сайлап алып һәйбәтләп әрчеде. Кабат чайкаганнан соң вак кына итеп турап чиләккә салды.

Ит консервыларының берсен ачып, кырып-сыпырып чиләккә бушаттым. Савытын бер читкә ташладым. Аның шалтырап ташлар арасына барып төшүе әллә кайларга ишетелде. (Гомумән монда һәрбер аваз шулай кирәгеннән артык көчле булып яңгырап ишетелә.)

Булгач булсын инде дип, ашка тоз белән бергә икеөч лавр яфрагы да йөздереп җибәрдем. Суган турарга да онытмадык.

Аш пеште. Җәелгән палатканың итәгенә табын әзерләдек. Әмма аш бүлгәндә Актүшкә савыт җитмәгәнлеген абайлап алдык. Мин җәһәт кенә урынымнан сикереп торып фонарьны кабызып алдым да бая ыргыткан консерв банкасын эзли башладым. Әле ярый, таш-фәлән арасында югалмаган, бик тиз таптым.

Ашап туйганнан соң табындагы азык-төлекне целлофан капчыкларга салып, барысын бер рюкзакка тутырдык, аннары инде агачның өскә таба тырпаеп торган тамырына элеп куйдык. Ризык запасын күз карасы кебек саклау иде безнең ниятебез.

Шуннан соң үзебезчә бер план кордык. Без агып төшкән шарлавык тирәсен тикшереп килергә булдык. Бәлки әле өскә күтәрелерлек берәр урыны бардыр?..

Суга яланөс, трусик белән генә керәсе иттем. Шулай да аякларга кедаларымны киеп алдым. Су төбенең нинди икәнен кем белгән? Аннары җир асты елгасында ниләр генә булмас?.. Сөлектер, кысла кебек төрле хәшәрәттер.. Бәлки әле алардан яманрак нәрсәләр дә бардыр?..

Шундый уйлар белән су кырыена килеп бастым. Бер кулымда фонарь, икенчесендә палатканы, киемсалымнарны элеп киптергән озын колга. Су өсте шыксыз, нефть кебек чем кара төсле. Суга керсәң, тәнеңә йогып калыр шикелле. Бу минутта мин үземне крокодиллар мыжгып торган Амазонка елгасы буена килеп баскандай хис иттем.

Чишенеп ташлавыма үкенеп тә куйдым. Әллә киенимме икән? Юк, ярамый. Марсиянең: курыкты, дип уйлавы бар...

Шул чак Әл-Хәлил дустым сөйләгән бер хикәя искә төште. Карл беренче эшафотка барыр алдыннан ике кат күлмәк кия. Ни өчен? дип сорагач, ул: «Әгәр иртәнге салкыннан калтырансам, дошманнарның куркып калтырады дип уйлаулары бар. Мин андый түбәнлеккә төшә алмыйм», дип җавап кайтарган ди.

Минем дә Марсия алдында сер бирәсем килми.

Колга белән төпне капшаштыргалап, билдән тиң суга кердем. Төбе лайлалы-ләмле түгел, шактый нык. Сирәк-мирәк кенә ташлар, баткан агач ботаклары очраштыргалый. Менә, искәрмәстән генә, ботыма нәрсәдер кагылып киткән сыман булды. Чак кына кычкырып җибәрмәдем. «Сынган чыбыктыр яки балыктыр» дип, үз-үземне тынычландыргандай иттем.

Ләкин балыкларның да төрлесе була бит. Әнә, Бразилиянең төньяк-көнчыгыш елгаларында, сусаклагычларында пиранья дигән балыклар яши икән. Үзләре зур булмасалар да, ил өчен тәмам афәткә әверелгәннәр. Су фаунасындагы җан ияләрен шундук юк итәләр, имеш. Хәтта... крокодилларга да ташланалар икән. Әмма тегеләре хәйләкәр, пираньялар өерен күрү белән, су өстенә калкып, тәпиләрен өскә күтәреп, чалкан яталар ди. Чөнки крокодилларның аркасындагы мөгезсыман панцирына пираньяларның тешләре үтми икән...

Пираньялар яшәгән елга аша көтүләрне чыгарганда иң элек берәр үгезнеме, сыернымы аерып алып, агым буенча чак кына аскарак төшереп, суга куып кертеп җибәрәләр икән. Күп тә үтми, аларның сөякләре генә кала икән. Аның каравы көтүчеләр мал-туарны су аша исән-сау алып чыгалар икән.

Шундый уйлар эчендә шарлавыкка якынлашып киләм. Ә ул, тирә-якка ак күбекле дулкыннарын таратып, бер көйгә генә гөрелди...

Менә мин шарлавыкның каршысына ук килеп җиттем. Су, галәмәт зур көч белән, биш-алты метр биеклектән ургылып төшә. Тирә-як кайнаган сыман актарылып-бөтерелеп тора. Тәнне чиркандырып өстемә тамчылар чәчри. Шарлавыкка якынайган саен су төбе тирәнәя бара. Менә су минем муеныма җитте. Ә үзем, фонарь белән яктыртып, тирә-юньне күздән кичерәм...

Әйе, безнең хәлләр яман булырга охшый. Шарлавыкның аръягында да тоташ стена. Ул гранит кыя булып мәгарә гөмбәзенә барып тоташа. Бары тик өстә, шарлавык ургылып чыккан җирдә генә, куыш сыман нәрсә бар.

Әллә кычкырып карарга мы икән? Бәлки, ишетерләр...

— Ә-әй-й-й!.. А-ууу!.. Без-з мо-он-нда-а!..

Минем тавыштан мәгарә эче яңгырап китте. Мин җавап-фәлән булмасмы дип бар игътибарымны туплап, колак салып тыңлыйм. Юк, ул-бу ишетелми. Бары тик мине үчекләгәндәй итеп: «мо-он-онда-а!..» дип кайтаваз гына җавап бирә.

Шарлавык янында озаграк торган саен өметем өзелә, өметем киселә генә барды. Без агып төшкән юлдан күтәрелү турында уйларга да ярамый. Алайса нишләргә соң?..

Бар борчылганым — Марсия. Их, Данко кебек, ялкынланып торган йөрәгеңне баш өстенә күтәр идең дә: «Әйдә, Марсия! Калма минем арттан...» дип, аны кояш иленә, җир өстенә алып чык идең.

Марсия, тирә-якны яхшырак яктырту нияте белән, учакка коры-сары өстәп тора. Мин дә тик тормаска, безнең учак төтене һәм әлеге шыксыз ярканатлар кереп югала торган тау куышы тирәсен күзәтеп килергә булдым.

Чыннан да, шул кадәрле мул сулы елга кая булса да агып чыгарга тиештер бит. Бу турыда мин Марсиягә дә әйткән идем. Бик тә хәтәр, ниндидер зур җанвар өнен хәтерләтеп торган шул тау куышына хәзер инде без сүз белән әйтеп аңлатып булмаслык яшерен бер өмет белән карый башлаган идек.

Сагаеп кына җир асты елгасы кереп югалган куышлыкка якынлашам. Су сизелерлек тирәнәйде, ә агым көчәйде. Фонарь яктылыгы тау куышын айкый... Бу тирәләрдә елга, каядыр ашкынган сыман, текә ярлар арасына атылып барып керә. Ул тирәләр һич тә киемсалым, биштәр-рюкзак күтәреп үтәрлек түгел. Шул чак кылт итеп башыма бер уй килеп төште: «Ә сал ясап карасак?»

Бу хакта Марсиягә әйткәч, ул минем фикергә колак салу түгел, тыңларга да теләмәде.

— Син нәрсә, коткару партиясе турында оныттың дамыни? Кинәт монда килеп төшсәләр? Алар төшкән-

дә без булмасак? — дип, ул бер-бер артлы сораулар яудыра башлады.

Мин:

— Әйе шул, шулай шул,— дип, аның сүзен җөпләргә мәҗбүр булдым.

Ничек тә безне мондый хәлдә калдырырга тиеш түгелләр. Шарлавык буенча төшә алмыйлар икән, икенче юлын табарлар. Һич югында зур диаметрлы бораy белән мәгарә түбәсен тишеп, шуннан төшәрләр...

Мин күз алдыма гадәттә вертолеттан төшерелә торган, чайкалып торган тар гына асылма баскычны китердем. Әлбәттә, коткарачаклар! Хәзерге могҗизалар чорында андый гына эшләрне эшләмиләрме соң?!

Көтәргә кирәк, сабыр итәргә!..

ХӘРӘКӘТТӘ БӘРӘКӘТ

Әмма бер көтелмәгән вакыйга бөтен уй-ниятләребезне челпәрәмә китерде дә ташлады.

Ягар өчен коры-сары җыярга дип чак кына читкәрәк киткән Марсиянең искәрмәстән үзәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрүеннән тетрәнеп киттем. Аңар Актүшнең дә яман өрүе кушылды...

Менә алар, ташлар, аркылы яткан агачлар аша сикереп үтеп, мәтәлә-кадала дигәндәй йөгерешеп, ут янына килеп җиттеләр. Марсия күзләрен йомган, чырае калмаган, үзе еш-еш сулый иде.

— Нәрсә бар?.. Нәрсә булды? — дидем мин, пошаманга төшеп. Марсиянең авызыннан бары тик бер сүз чыкты:

— Кеше...

— Нәрсә?!

— Анда... кеше.

Бу хәбәр мине әллә нишләтеп җибәрде.

— Нинди кеше? Кайда?..

— Әнә тегендә... Почмакта.

Башымнан яшен тизлеге белән бер уй чагылып узды. Бәлки, безне коткарырга төшкән кешеләрнең берәрседер?

— Кайда соң ул?

— Әнә, тегендә...— диде Марсия, һаман да әле тынычлана алмыйча.— Скелет ул...

Бу сүзне ишеткәч бөтен җирем туңып китте.

— Кайда?.. Әйдә күрсәт,— дидем мин, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.

Фонарьны үз кулыма алдым. Мәгарәнең түренә, бер почмаккарак киттек. Һәм чыннан да, текә стена буенда, кечкенә генә бер ачыклыкта, тешләрен ыржайтып бер кеше скелеты ята иде. Гәүдәсе өлешчә чүпрәк-чапрак белән капланган сыман. Мин таяк белән аның кием шикелле кара-кучкылланып торган сәләмәләренә кагылдым. Әмма алар, янган кәгазь көле кебек, шундук таралып төштеләр. Мәңгелек караңгылыкка эләккән бу кеше гәүдәсе бик күптәннән бирле ята булса кирәк.

Ниндидер юллар белән, ниндидер бәхетсезлеккә очрап, шушы шыксыз куышта әҗәлен тапкан кешенең көл булып таркалырга торган сап-сары скелетын күргәч күңелем әллә ничек актарылып киткәндәй булды. Безнең дә бит әнә шулай бу куыштан мәңге чыга алмый калуыбыз бар. Кояшны, якты җир өстен бүтән беркайчан да күрә алмавыбыз бар...

Димәк, безгә кемнәрнеңдер каяндыр килеп коткаруларын көтеп утыру ярамас. Минем әби кул кушырып утырганны бер дә яратмый. «Хәрәкәттә бәрәкәт» дип әйтә торган иде. Безгә дә ни дә булса эшләргә кирәк.

Һәм без шундук эшкә керештек. Минем сал ясар өчен күзләп куйган дүрт-биш агачым бар. Алар юан да, озын да, төз дә, ботак-тамырлары юк диярлек, үзләре су буена якын ук яталар иде.

Тирә-якка тук-тук итеп балта авазлары яңгырый, ә балта астыннан йомычкалар чәчрәп чыга башлады. Учак яктысы төшмәгән урыннарда Марсия фонарь белән яктыртып торды. Сабы-ние белән тоташ тимердән эшләнгән балта белән күпме иза чигелгәндер, белмим, әмма кулбашлар калмады. Уч төпләрем ут кебек кызышты.

Скелетны күргәннән бирле ничектер куркынып калган Марсияне юатырга да кирәк иде. Шуңа күрә үзем ботак-тамыр чабам, үзем сөйләнгәләп алам:

— Тур Хейердалны хәтерлисеңме? Аның «Кон-Тики» салында сәяхәт итүен... Аннары камыштан ясаган «РА-1», «РА-2», соңрак «Тигрис» көймәләре белән... Үкереп торган океанга экспедициягә чыгып китүен?

Ә бит анда акулалар, китлар, тагын әллә нинди су җәнлекләре мыжгып тора...

Кулымның әрнүенә чыдар хәл юк. Тур Хейердалга аңа әнә көймәләрен Боливия индеецлары ясап биргән. Монда менә минем үземә чиләнергә туры килә.

Тәмам ардым. Аякта чак басып торам. Әле дә ярый, чиләктә кайнатып куйган салкын чәй бар. Киләм дә эчәм, киләм дә эчәм. Маңгайдан агып төшкән тир күземне чылатып әчеттереп-әчеттереп ала.

Үч иткән кебек, ашыйсы килә башлады. Әмма бу турыда ләм-мим. Азык-төлек бик чамалы. Икмәк, Ленинград блокадасындагы кебек, өлешләргә, «паек»ларга бүленде. Әмма сизенеп торам, көнме-төнме икәнлекне белмәгәнгәме, «паек» өләшүне ешайттык шикелле.

Үзебез түзәр дә идек, әмма Актүш бик сабырсыз булып чыкты. Атларга да ирек бирмичә шыңшып, ашарга сорап, аяк астында бөтерелә. Кызганып, үз паегыңнан булса да бармак башы кадәрле генә икмәк сындырып бирергә мәҗбүр буласың.

Тирә-юньдә ашарга яраклы нәрсәләр күренми. Балык, кысла ишеләр юкмы икән дип, фонарь белән су төпләрен дә яктыртып караштырган идем. Ник бер җан иясе булсын. Ярканатлар да (төтеннән куркыптыр инде) безнең тирәдән каядыр китеп югалдылар. Анныры аларны ничек итеп аулыйсың ди? Тоткан тәкъдирдә дә ничек итеп ашамак кирәк...

Ниһаять, сайлап алынган биш агачның бишесен дә ботак-тамырларыннан арындырып бетердем.

Чак кына ял итеп алгандай иттек тә яңадан эшкә керештек. Иң элек колга-рычаглар ярдәме белән бүрәнәләрне суга тәгәрәтеп төшердек. Аннары бергә җыйдык. Авыр икән болай сал ясау. Такта, пычкы, кадаклар булса икән әле. Алар булса, мин салны коеп кына куяр идем.

Әбием: башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дн торган иде. Уйлый торгач, бүрәнәләрне бер-берсенә беркетү әмәле дә табылды. Моның өчен без палатканың як-якка тарттырып куя торган сүс бауларын файдаланырга булдык.

Күпмедер вакыт тырыша торгач, биш бүрәнәдән генә ясалган салыбыз: мин сәфәргә әзер! дигән кебек, су өстендә чайкалып тора иде инде.

АСЫЛТАШЛАР МӘГАРӘСЕ

Кузгалып киттек...

Беренче тапкыр сыенып урын тапкан мәгарәдә тирәякны яктыртып безнең учагыбыз янып калды. Без елга ярып үткән тау куышына килеп кергәч, ул өмет йолдызыбыз да сүнгәндәй булды. «Коткаручылар килсә, безне бит иң элек шушы тирәләрдән эзләячәкләр...» дигән уй күңелне кабат сыздырып куйды. Ямансу булып китте. Хәзер инде без теләгән тәкъдирдә дә ул тирәгә кире борылып кайта алмаячакбыз. Чөнки безнең сал көчле агымга эләгеп, шактый зур тизлек белән һаман алга таба ага...

Сал өстендә дә ут яна. Агачларга ут капмасын өчен, иң элек бүрәнәләр өстенә яссы ташлар тездек. Аннары шактый калын итеп балчык түшәдек. Бары тик шуннан соң гына, учактан янып торган кисәүләрнең бер өлешен сал өстенә күчереп, ут ягып җибәрдек.

Сәяхәтебез дәвам итә.

Сал һаман алга йөзә. Колгамны суга тыккалап тирәнлекне чамалап барам. Урыны-урыны белән су бөтенләй төпсезгә әйләнә. Ә як-ягыбызда ташкүмергә охшашлы текә ярлар ялтырап куя. Алар әледән-әле үзгәреп, алышынып тора. Мине бер уй куркыта: берәр су асты кыясына туры килеп бәрелә-нитә калсак, баулар һәм аркылы салынган колга сыман агачлар белән генә ныгытылган салның таралып китүен көт тә тор!..

Ут салның алгы өлешендә яна. Икенче башында утыннар өелеп куелган. Шул тирәдә үк рюкзакларыбыз, азык-төлекләребез, савыт-сабаларыбыз өчен бура сымак бер нәрсә ясап куйдык. Сал уртасына палатканы җәйдек. Актүшнең урыны шәп: капитан кебек, утын әрдәнәсенә менеп утырды ул.

Бераздан елга киңәеп, текә ярлары чак кына читләшкән сыман булды. Баш очыбыздагы мәгарә гөмбәзе дә биегәйде. Агым да чак кына тынычланды кебек.

Тагын шунысы күзгә ташланды: башта кара-кучкыл булып күренгән ярлар кинәт үзгәрделәр, известьташка охшап калдылар. Әллә сланец катламнары башландымы икән? дигән уй туды миндә.

Шулай дип уйларга да өлгермәдем, алда тоныкына яктылык чагылып киткәндәй булды. Мин тиз генә

фонарьны алып кабыздым да яктылык көлтәсен шул якка юнәлдердем.

Бераздан безнең сал искитмәле матур, шактый киң мәгарәгә килеп керде. Як-ягыбызда, ап-ак мәрмәр колонналарны хәтерләтеп, сталагмитлар утыра. Аларның өске өлешләре очлаеп килгәннәр. Баш очыбызда, киң мәгарәнең бөтен түшәмен биләп, шундый ук аксыл төстәге сталактитлар асылынып торалар. Тирә-юнебез, сал өстендә янган учак яктысында, елык-елык килеп ялтырый иде.

Шунда, уң яр ягыннан, чылтыр-чылтыр чишмә акканы ишетелде. Фонарь яктысын җәһәт кенә шул якка бордым. Бордым да хәйран булдым. Анда кояш нурында ялтыраган көзге кыйпылчыклары, пыяла ватыклары сыман, аллы-гөлле нурлар чәчеп, вак ташлар чәчелеп ята иде.

— Марсия!..— дидем мин, үземнең соклануымны яшерә алмыйча.— Бу якка кара әле...

Бу күренеш аны да хәйранга калдырды.

Мин тиз генә салны шул якка бордым. Ярга чыктык. Гадәттән тыш матур уенчык күргән бала-чага кебек, икебез дә боздай салкын су өстенә иелдек. Су төбе күзләрне камаштырырлык асылташлар белән тулган. Аларның чик-чамасы юк иде.

— Менә, Марсия, күр... Чын алмаз бу. Табигатьтә иң каты матдә...

— Нишләп соң алар төрле төстә?

— Алар төрле төстә булалар да. Билгеле, аксыл-сары төстәгеләре ешрак очрый. Әмма, геологлар белән спелеологларның әйтүенә караганда, алмазларның кара төстәгеләре дә була икән...

— Ә болары нәрсә? Нинди ташлар?..— дип сорап куйды Марсия. Карасам, шаккаттым: кристаллар!

— Боларымы?..— дидем мин бик белдекле кыяфәт белән.— Болары, үтәдән-үтә күренмәлеләре, кристаллар... менә күр, нинди төстәгеләре дә бар. Зәп-зәңгәре, күкселе... менә тагын нинди матуры... Шомартканнан соң мондый кристалларны бриллиант дип атыйлар. Иң кыйммәтле асылташ булып санала ул.

— Ә болары нәрсә?

Марсиянең учында үтәдән-үтә күренмәле вак түгәрәк шарлар җемелди иде.

— Белмим,— дидем мин.

Шулай да, андый «пыяла ядрәләр» турында укыганлыгым исемә төште. «Аполлон-11»дә очкан Армстронг та ай өстендә менә шушындый «пыяла ядрәләр»гә охшаган минераллар тапкан булган.

— Бәлки, мәгарә энҗеседер?..— дидем мин, кызның соравына тиешенчә җавап бирә алмавыма уңайсызланып.

Ул арада мин салдан буш консерв банкасы белән балта алып килдем. Маркшейлер кебек, мозаикага охшап торган кыя-стена кыйпылчыкларын китеп алгалый башладым. Тирә-юньдә чәчелеп яткан алмаз, кристалларны да бераз җыеп алдым. Менә кемдә булачак ул коллекциянең асылы!..

Әллә ни эчәсебез килмәсә дә, чиста-сафлыгына, салкынлыгына кызыгып су эчтек тә яңадан кузгалдык. Безне тәмам таңга калдырган, гаҗәеп таш чәчәкләр, әкәмәт асылташлар белән тулы «хрусталь зал» артта калды.

«ГАЛАПАГОС» УТРАУЛАРЫ

Актүшнең өрүенә сискәнеп уянып киттем. Кай арада шулай күзем йомылган соң? Ә, әйе! Бик аргач, ял итәргә яткан Марсия кырыена килеп утырып торган идем. Шунда оеганмын.

Карасам, учагыбызның ялкыны сүнгән, кызу бөркеп торган эре күмерләре генә калган. Иң элек утка коры-сары салдым. Аннары, фонарем белән яктыртып, тирә-юньне күзәтә башладым.

Салыбыз ашыкмыйча гына, талгын агым белән һаман алга йөзә. Ярларны хәтерләтеп торган кыялар шактый еракта. Димәк, елга киңәйгән. Баш өстебездәге таш түбә дә шактый биегәйгән...

Актүш салның алгы өлешенә чыгып баскан да һаман тынгысызлана, нәрсәдер сизенгәндәй ырылдый, хәтта чинап куйгалый.

Учакка тагын утын өстәдем. Фонарь яктысын яңадан алга таба юнәлдердем. Шул чак сәер бер күренеш күзгә чалынып калды. Алда, гадәттә таң алдыннан елга өстендә була торган куе ак томанны хәтерләтеп, ниндидер күләгәләр хәрәкәтләнә иде.

Нәрсә булыр бу?

Марсияне уяттым.

— Сиңа ничек күренә, ачыклык түгелме ул алда? — дидем мин, ак болытларны ни дип юрарга да белмичә.

Марсия күзен алга ташлап сискәнеп куйды.

— Әллә?..— Бер мизгелгә туктальш калды да өстәде: — Әллә җир өстенә чыгабызмы икән?

Их, шулай булсачы!

Безнең сал торган саен шул ак шәүләләргә якынлашып килә. Тирә-ягыбыз чак кына яктырып та киткән кебек булды. Ләкин бу көн яктылыгы түгел иде. Яктылык булудан бигрәк, кышкы төннәрдә генә була торган зәңгәр эңгер-меңгерлек иде бу.

Учак ялкыны көчәя төште. Икебезнең дә (Актүш турында әйткән дә юк) күзләребез алга төбәлгән. Елга тагын да киңәйгән сыман. Ә менә агым бөтенләй әкренәйде. Ул да булмады, өстебезгә җылы яңгыр сыман тамчылар тама башлады. Бу тирәнең һавасы да бик дымлы иде.

Бераздан безнең сал бик зур мәгарәгә килеп чыкты. Бу мәгарәнең ярларын күреп булмый. Алар урынына тирә-якта үзенә бертөрле сәер зәңгәрсу яктылык белән ап-ак пар гына тирбәлеп тора иде.

Нәкъ шул минутта, каршыга йөзеп чыккан кебек, зур гына утрау пәйда булды. Ул да түгел, безнең Актүшебез котырынып-ярсып өрә башлады. Утрауда ниндидер җан ияләре бармы әллә?..

Мин, озын колгамны су төбенә терәп, салны шул утрауга юнәлттем. Яр буйлары эреле-ваклы ташлар белән тулган. Шунда ук — аксыл төстәге камыш сыман үсемлекләр. Күп иде алар монда.

Эчемә җылы керде. Димәк, без тереклек дөньясына килеп чыкканбыз.

Ярга якынайдык. Шул вакыт ярда утырган бакаларның чупырдашып суга сикерүләрен, яр буеның мәш килүен абайлап алдым.

Сагая калдык. Шулай да салны яр буенарак бордым.

Баядан бирле өреп-ырылдап, ярга таба ыргылып торган Актүш, күз ачып йомганчы, җиргә сикереп төште дә нәрсәгәдер барып ябышты...

Колгамны төпкә кадап, салны ныгытып куйдым. Шунда күрдек: Актүшнең авызында беләк буе кәлтә

иде. Иләмсез озын, кызгылт төстәге бу сөйрәлүчеләр вәкиленең игуан икәнлеген абайлап калдым. Экватордагы Галапагос утрауларында яши торган игуаннар монда ничек килеп эләктеләр икән?

Әмма мине иң куандырганы тирә-юньдәге үсемлекләр иде. Димәк, бу тирәләр көн яктылыгыннан бөтенләй үк мәхрүм түгелләр...

Күңелем түрендә туган шул шатлыклы хисне Марсия белән дә уртаклашасым килде. Кызга сорау артыннан сорау бирәм.

— Я, әйт әле, Марсия... Агачка яфраклар ни өчен кирәк?

— Кояш нурларын тотып, аларны углеродка әйләндерү өчен, алмашка кислород ясау өчен, дымны аерып чыгару өчен.

— Ә тамырлары?

— Җирдә нык итеп берегеп тору өчен. Туфрактагы азыкны үзләштерү өчен.

Сизеп торам, Марсиягә дә җан керде.

— Молодец, Марсия! Бишлең бар дип санасаң да ярый. Тагын бер сорау сина: үсемлеккә серкәч белән җимешлек нигә кирәк?

— Серкәч серкә хәзерли, ә җимешлек үсемлекнең үрчү органы.

— Тузганак чәчәгенә «парашют» ни өчен? Өрәңгегә «канатлар» нигә? Тигәнәкнең кырмавыкларына «кармаклар» нигә кирәк?

— Якты дөнья буенча таралу өчен.

— Әйбәт, Марсия! Үткәннәрне онытмагансың. Әмма тагын сорау. Чәчәкләргә хуш ис нәрсәгә?

— Белмим.

— Ә ромашкаларга ак таҗ яфраклары ник кирәк дип уйлыйсың?

— Матурлык өчен...

Ярга төштек. Тирә-юньне җентекләп тикшерә, караштыра башладык. Иң элек камыш сыман аксыл төстәге үсемлекләргә игътибар иттек. Алар бик зәгыйфьләр. Баз төбендә, караңгыда онытылып калган бәрәңге сабаклары шикелле, кагылу белән сынарга гына торалар.

Әйе, болар кояш нурын күреп үскән үсемлекләргә охшамаган.

Утрау белән танышуыбызны дәвам итәбез. Аның җире бик үзенчәлекле. Аяк астында — тигезле-тигезсез, таш сыман каты җир. Бу җир кәтү йөргән сукмаклар кебек тар һәм такыраеп беткән юлчыклар белән аркылы-торкылы кискәләнгән. Без шундый сукмакларның берсе буйлап өскә таба күтәреләбез.

Актүшнең тамагы туйды булса кирәк. Ул, ләң-ләң килеп, бертуктаусыз өреп, кемнәр беләндер «талаша».

Аяк астыбыздан галәмәт шыксыз, әмма бик өлгер игуаннар йөгерешеп үтә. Гаҗәпләнгән сыман, чак кына безнең якка карап торалар да күз иярмәслек тизлек белән ташлар арасына кереп яшеренәләр.

Шунда Марсия кинәт кенә туктап калды.

— Нәрсә бу?..— дип, бик пошаманга төшеп, аяк астына күрсәтте.

— Кайда?

— Менә ич...

— ?!.

— Әнә, селкенә...

Без күтәрелә торган сукмак өстендә үк озынча таш сыман түгәрәк бер нәрсә ята. Җентекләбрәк карасам — ташбака. Галәмәт зур үзе. Безнең мәктәпнең зоопочмагындагы ташбакалар моның янында уенчык кебек кенә.

Ташбака безнең фонарь яктысын яратмады, ата каз кебек ысылдап алды да балык тәңкәседәй кабырчыклы кәкре муенын таш «күлмәге» эченә яшерде. Тик челт-челт итеп (утта чагылудан булса кирәк) күзләрен генә йомгалап ала иде. Алар монда байтак, бакчада үскән сары кабаклар кебек чәчелешеп яталар. Безнең Актүш шулар белән юана икән. Менә ташбакаларның берсе, шактый олысы, безнең аяк астында ук. Уенчык танк сыман, әкрен-салмак хәрәкәтләнеп, качып китеп бара. Шомарып беткән сукмаклар аларның гасырлар буена йөргән юллары икән.

Игуаннар һәм ташбакалар белән очрашкач, «Галапагосы — зачарованные острова» * дигән китап исемә төште. Искитмәле могҗизалы утрау турында ул. Анда һәркайсы өчәр йөз килограмм авырлыктагы ташбакалар яши. Утрау үзе Тын океан уртасында, материклардан меңнәрчә километр читтә утыра. Галапагос утрау-

---

* Атаклы зоолог Иренеус Эйбль-Эйбесфельдт әсәре.

лары шул гигант ташбакалар архипелагы ди. («Галапагос» испанча «ташбака» дигән сүз.)

Билгеле, борын-борын заманнарда, моннан 60 миллион еллар элек гигант ташбакалар белән бөтен җир шары тулган булган. Нью-Йорктагы тарихи музейда бер шундый гигант ташбаканың панциры саклана. Галимнәрнең әйтүенә караганда, аның авырлыгы тоннадан да артыграк икән.

Ул утрауда Чарльз Дарвин да булган. Аның язуына караганда, дөньяда шул гигант ташбакаларның итеннән дә тәмлерәк ит юк икән. Итләренә кызыгып, аларны бөтенләй юк итеп бетерә язганнар. Баштарак пиратлар, соңрак кит аулаучылар һәм сәүдәгәрләр, утрау янына туктап, үзләренең кораблары трюмына берьюлы утызар, хәтта аннан да артыграк тонна ташбакалар төяп китә торган булганнар. Кораб трюмына тутырылган ташбакалар ел ярым чамасы ашамыйча-эчмичә яши ала икән. Менә шул сыйфатлары аркасында алар җир йөзеннән бөтенләй бетә язганнар.

ҺӨҖҮМНӘН ҚАЧАБЫЗ

Без тагын бер нәрсә белән кызыксына калдык: болыт сыман булып тирә-юньгә таралган бу ак томан каян чыга?

Ниһаять, белдек. Утрауның икенче ягында, ургылып-атып торган берничә гейзер бар икән. Ак пар да, кайнар чишмәләр дә шуннан чыга. Ул яктан, болкылдап кайнаган авазлар белән бергә, үзенә бертөрле эссе бөркелеп тора.

Қарасак, кайнар сулы ерганак аръягында — тагын шундый ук эреле-ваклы утраулар тезмәсе. Аларда да ташбакалар, шыксыз игуаннар мәш килә.

Бу тирәнең яр буйларында җикән белән күрән үләненә охшашлы үсемлекләр башка урыннарга караганда мулрак. Су буенда яткан ташлар, эрерәк тау токымнары тутык төсендәге мүк сыман үсемлекләр белән капланган.

Су төбен күзәтәм. Фонарь яктылыгы үтеп кергән саерак урыннарда, ләмле төптә — моллюск кабырчыклары. Шунда ук төрле кортлар, ялтыравыклы бөҗәкләр, йөзгәләк коңгызлар һәм кысласыман экәм-төкәмнәр. Су-

үсемнәр дә бар. Алар, төссез мунчала кебек, агымда чайкалып-тирбәлеп торалар. Вак-вак тәңкә булып, ак-сыл-яшел төстәге үсемлекләр дә йөзеп үткәли. Кем белә, бәлки, балык та бардыр?.. Ләкин, күпме генә караштырсам да, балыкка, һич югында кыслаларга охшашлы җан ияләре күренмәде.

Бу могҗизалы утрау янында озак юандык. Җан ияләре очраган җирдән тиз генә аерылып китәсе килми. Алда ни көткәне билгесез бит...

Шулай да салыбыз янына кайттык, утны ягып җибәрдек. Тирә-як кинәт яктырып китте. Актүш, шуны гына көтеп торган кебек, яңадан ярга ташланды. Яңгыравык тавышы белән әле уңга, әле сулга ыргылып, һаман игуаннар белән шаяра...

Кузгалып киткәнче, иң элек капкалап алырга булдык. Мин, тиз генә ярга чыгып, бер ташбака тотып алдым. Шул чак Марсия:

— Нишләтмәкче буласың аны?..— дип сорап куйды.

Мин ачыктан-ачык әйттем. Әмма Марсия, коточкыч сүз ишеткән кебек, кулларын гына селтәде.

— Ачка үлсәм үләм... Әмма ашамаячакмын,— диде ул.

— Менә пешереп күрсәтим әле. Аннары әйтерсең,— дидем мин, һаман да үзсүзләнеп.

Үзем уйга калдым. Ә ничек пешерергә аны? Билгеле, күтәреп алып ташка бәрсәң, панцирьы ватылыр... Ташбака да үләр. Тик алай итәргә кул күтәрелерме? Бәлки, суяргадыр?.. Ләкин бит минем моңарчы чеби суйганым да юк.

— Тотам да суям!..— дидем мин.

Марсиянең гаҗәпләнүе бу юлы да тавышына чыкты:

— Синме?

— Ә нәрсә?.. Кем булсын тагын... Робинзоннар икәнбез, Робинзоннар булырга кирәк...— Ә үзем: «Их, балыклар булса, ташбакага тимәс тә идек», дип уйлап куйдым.

Үзем сөйләнәм, ә үзем кечерәк ташбакаларны салга ташыйм. Дүртнеме, бишнеме керткәч, бу эштән бүленергә туры килде. Яр буенда мәш килеп йөргән Актүшкә әллә нәрсә булды. Кинәт елап-чинап җибәрде. Ул да булмады, корт чаккан сыман, атылып килеп салга сикерде.

Нәрсә булыр бу? Нәрсәдән шулкадәр курыккан ул?.. Карасам, ташлар арасыннан, агым су кебек салмак хәрәкәтләнеп, иләмсез юан бер елан төшеп килә иде.

Аны Марсия дә күреп алды.

— Камил!..— дип кычкырып җибәрде.— Тизрәк китик...

Мин, җәһәт кенә җиргә сикереп төшеп, салны этеп җибәрмәкче идем. Әмма ул урыныннан кузгалмады. Бая мин кадап куйган колга тоткарлап тора икән.

— Марсия!.. Тиз бул... Колганы ал...

Марсия селкеткәләп колганы йолыкканчы шактый вакыт үтте. Елан да якынайды. Сал өстендә янган ут яктысында мин инде аның кара тәңкәләр белән чуарланган саргылт төсен дә, кимендә биш-алты метр озынлыкта булуын да абайлап алдым.

Салны урыныннан кузгатып, җан-фәрманга этеп җибәрдем дә үзем дә сикереп мендем. Бу хәтәр җирдән тизрәк китеп котылырга кирәк иде.

Елан да суга төште һәм, як-якка дулкыннар җибәреп, гаять зур тизлек белән салга таба якынлаша башлады.

Елан якынлашкан саен, Актүшнең дә чинап өрүе көчәйде, аның тавышыннан бөтен мәгарә яңгырап торды.

Елан безне бик тиз куып җитте. Мин инде аның сузылып йөзгән гәүдәсен генә түгел, нурсыз күзләренең салкын елкылдавын да аермачык күрәм. Питонның комсыз ачылган авызында — аслы-өсле икешәр очлы теш. Хәнҗәр кебек үткен булып, кара-каршы килгән бу елтыр тешләр чак кына эчкә таба ятыбрак торалар.

Аждаһа, салга бәйләп куйган диярсең, бер генә метрга да калышмый. Шыксыз күзләре Актүштә. Ул инде, этне эләктерергә чамалап, бер-ике тапкыр муенын да сузгалап алды. Бу хәлне сизенгән Актүш чинапелап салның арткы өлешенә, Марсия янына ук барып посты.

Питон салдан калу турында уйламый да. Болай булса, әллә ни тартынып тормас, сал өстенә менүе дә ихтимал.

Колгам белән кизәнеп сукмакчы да идем. Кая ул! Шундый елгыр, һич тә суктырмый. Ата казныкы кебек хәрәкәтчән башын я уңга, я сулга тайпылдырып кына кала.

Менә аждаһа салга үрмәли башлады. Мин, ни булса шул булыр дип, учактан зур гына утлы кисәү алдым да яртылаш диярлек сал өстенә менгән еланның канга буялган сыман алсуланып торган бугазына тыгып куйдым...

Шунда бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Питон бөтерелеп килеп, бөтен гәүдәсе белән судан атылып чыкты. Безнең баш өстебездән чажылдап очып, бер кырыйга барып төште. Һәм, тирә-якка күбек катыш су фонтаннары чәчрәтеп, үрле-кырлы сикеренгәләп чәбәләнә башлады. Без, колгаларыбыз белән тагын да җәһәтрәк эшләп, ул тирәдән тизрәк китү ягын карадык...

ДИНОЗАВРЛАР ӨНЕНДӘ

Күпме вакыт һәм нихәтле юл үтелде икән инде? Белмибез. Ә салыбыз һаман ага да ага.

Җир асты елгасына тагын берничә инеш килеп кушылды. Су да тирәнәйде, күзгә күренеп киңәйде.

Ярлар әледән-әле үзгәреп торалар. Вакыты белән шактый эчкә кереп торган зур гына тугайларга килеп чыккалыйбыз.

Әмма безнең анда-монда кайгы юк, һаман алга таба йөзәбез. Питон һөҗүменнән соң, тирә-юньне дикъкать беләнрәк күзәтәбез.

Актүшнең искәрмәстән ырылдап өрә башлавыннан икебез дә сискәнеп киттек. Сал өстендәге ташбакаларга өрүе икән. Алар хәзер безнең салда икәү генә калды. Башкалары елан куганда төшеп калган. Болары да качмасын дип, без аларны бушап калган рюкзакка тыгып, капчыкның авызын тарттырып бәйләп куйдык. Ташбакаларның берсе капчыкны тишкән дә, шуннан башын, кәкре муенын чыгарып, безнең калган өч бәрәңгенең берсен ашап маташа икән. Ярты бәрәңгедән җилләр искән.

Бер заман үгез үкерүен хәтерләтеп, җан кайтаргыч аваз ишетелде. Берьюлы берничә җиз быргы кычкыртуын хәтерләтә иде ул.

Актүшебез дә, койрыгын кыса төшеп, безгә таба елышты.

— Нәрсә булыр бу?

Марсиянең зур булып ачылган күзләрендә курку галәмәтләре.

— Белмим шул...

Тагын кабатланмасмы дип, күпме генә колак салып тыңлап торсак та, шомлы аваз бүтән ишетелмәде. Без белмәгән берәр җәнлек яки кош-фәлән кычкыргандыр дип, үз-үзебезне тынычландыргандай иттек.

Сал әкрен генә әлеге аваз килгән якка таба ага. Агым сизелерлек кимеде. Каршыдан, тәннәрне чиркандырып, салкын һава бөркелә башлады. Учак ялкыны да як-якка ава-түнә селкенгәли. Һава агымыннан ук сизелеп тора, безнең алда ниндидер зур ачыклык булырга тиеш.

Әмма никтер ул якка күңел тартмый. Утын бетүен дә искә алып, салны ярга таба бордым. Бу тирәдә өем-өем булып бик күп агач кәүсәләре ята иде. Яр буена җитү белән, казыгымны салның бүрәнәләре арасыннан су төбенә кадап куеп, ярга сикердем.

Ләкин мин ауган агачлар дип уйлаган нәрсә безгә утынга ярамады, ниндидер галәмәт зур, гигант тереклек иясе скелеты иде ул.

Фонарь яктысында караштыра башладык.

— Нәрсә скелеты булыр бу?..

Марсия дә аптырашта.

— Кабыргаларын гына күр әле син аның... Сузылып буең җитәрлек түгел...

Төрле яктан караштырабыз.

Скелет елганың иске юлын хәтерләткән үзәнлекне биләп ята. Менә — баш сөяге. Казык тешләре. Шунда ук — яңак сөяге, һәркайсы иләмсез зур. Сөяк тавының тирә-ягында, эре калканнарны хәтерләтеп, кабырчыклар аунап ята.

Әллә без китаплардан гына укып белгән «динозавр скелеты» микән бу? «Зоология» китабында динозаврлар турында мондый сүзләр бар иде. Күңелдән хәтерлим: «Динозаврларның кайберләре 40—50 тонна авырлыкта һәм 25—30 метр озынлыкта булган. Мондый гигант хайваннар үсемлекләр белән тукланганнар. Ләкин динозаврларның бер өлеше гаять комсыз ерткычларга әверелгән. Шунлыктан, икенче төр динозаврларда махсус үсентеләр: шыксыз тырнаклар, мөгез-панцирьлар һәм башка төрле саклагыч җайланмалар барлыкка килгән».

Безнең мәктәпнең зоокабинетында аларның берничә рәсеме бар. Диплодок һәм бронтозаврлар дүрт аякта йөргәннәр, үсемлекләр белән тукланганнар. Игуанодан дигәне үзенең чамадан тыш зур булуы белән аерылып торган. Ә траходантлар белән манжурозаврлар үрдәкборынлыларга керәләр. Стегозавр — муеныннан алып койрыгына кадәр чәнечкеләр белән капланган булган. Аккилозаврлар — танк сыман авыр гәүдәле, салмак хәрәкәтле, кыска аяклы. Иң яманы, әлбәттә, тираннозаврлар. Галәмәт зур авызлы, эре тешле коточкыч ерткычлар. Ике аякта алпан-тилпән килеп бик нык йөгерә торган булганнар алар. Тираннозаврлардан качып котылу мөмкин булмаган...

Сизеп торам, Марсия дә юлны дәвам итик дип атлыгып тормый. Алай гына да түгел:

— Ардым, кыл өзәр хәлем калмады... Ут ягып җылынып, бераз ял итик,— диде. Мин дә риза булдым.

Аннары Актүшнең үз-үзен тотышы да сәер тоелды миңа. Якын-тирәдә ниндидер җан иясе барлыгын тойгандай, без барасы якка карап, чинау катыш ырылдап куя.

Яңадан салга кердек. Беребезнең дә сөяк тавы янында каласы килми. Актүш тә бездән бер адымга да калмый. Сал өстенә дә беренче булып ул сикереп менде.

Иң элек учакка утын өстәдем. Марсия, салга керү белән, палатка итәгенә төренеп утырды да: «Туңам!»— дип хәрәкәтсез калды.

Бар борчылганым Марсия. Яшерен-батырын түгел, минем инде: «Их, аның урынында берәр малай булса...»— дип куйган чакларым да булгалады. Ни әйтсәң дә, кыз кеше бит. Андый чакта малайларга ни җитә!

Шулай да Марсиянең күңелен табу нияте белән сүз кушам.

— Я әле, Марсия, әйтеп кара... Нәрсә ул изотерма?.. (География дәресен исеңә төшер дип тә өстәп куям.)

— Изотерма... Изотерма — тигез җылылык дигән сүз,— диде Марсия һәм шундук ялгышын төзәтеп өстәде.— Картадагы бертөрле температуралы урыннарны тоташтырган сызыклар изотермалар дип аталалар.

— Молодец, Марсия! Тагын бер бишлең бар дип санасаң да ярый...

Әмма аның сөйләшәсе дә килми. Палатка итәге белән баштанаяк төренде дә ятты. Ә мин, үз уйларыма бирелеп, учак янында утыра калдым. Бая бөтен мәгарәне тетрәткән тавыш тынычлыгымны алды. Ул аваз әле дә колак төбемдә яңгырап тора.

Тагын уйлар. Җитмәсә берсеннән-берсе шыксызлар, берсеннән-берсе күңелсезрәкләр... мин башка нәрсә турында уйларга тырышып карыйм... Марсия... менә ул минем кул сузымында гына... Иң якын күргән кешеләремнең берсе ул. Аның белән күбрәк вакыт бергә булу өчен мин хәтта бер-ике тапкыр яшь астронавтлар түгәрәгенә дә кергәләдем. Беренче тапкырында мең төрле астероидлар, метеоритлар турында әңгәмә алып бардылар. Әллә ни кызыгын тапмадым. Аның каравы икенче тапкырында сүз «Кызыл планета»— Марс турында барды. Безнең ил космик аппаратлары, Американың «Маринерлары», «Викинглары» ярдәмендә җентекләп тикшергәннән соң галимнәр әлеге планетада кабат тереклек бар дигән карарга килгәннәр. Әмма, галимнәр әйтүенчә, Марс туфрагын Җиргә алып кайтып анализлар ясауның ике төрле хәл ителәсе мәсьәләсе бар икән. Беренчесе — Марстан Җиргә кайтып җиткәнче үтәчәк ике ел чамасы вакыт эчендә тикшерүгә алынган туфрактагы микроорганизмнар үлеп бетәчәкләр ди. Ә икенчесе — иң хәтәре, әлеге микроорганизмнар Җирдәге уңай шартларга эләккәч, кинәт бик нык үрчеп китеп, көтелмәгән катастрофага китерүләре ихтимал дип уйлыйлар ди галимнәр...

Шушы тирәгә җиткәч, яңадан фикер эзлеклелегемне җуйдым. Башыма яңадан кирәкмәгән уйлар килә башлады. Шунда миңа, ни өчендер, яр буе үзәнлеген тутырып яткан скелетның баягы тавышка нинди дә булса бәйләнеше бардыр кебек тоела башлады.

Чыннан да, динозаврларга монда яшәү шартлары бармы соң? Булмаса, бу сөяк тавы каян килеп эләккән? Җир асты мәгарәләрендә, күргәнебезчә, тереклеккә яшәү өчен бөтен шартлар диярлек бар. Бәлки әле бу җир асты куышлыкларында, тирән күлләрендә динозаврларның өннәре дә бардыр? Ул гаять зур сөйрәлүчеләрнең дөньяның төрле почмакларында очраштыргалап торулары турында укымаган, ишетмәгән кеше юктыр. Безнең илдә дә аларны берничә урында очратканнар. Зоология дәресендә динозаврлар турында үт-

кәндә Әл-Хәлил шул хакта язылган берничә газета һәм журнал алып килгән иде. Алардагы мәкаләләрне бөтен класс белән кычкырып укыдык. Якутиядә, мәсәлән, Хайыр дигән күлдә әлеге коточкыч җанварны берничә тапкыр күреп калалар. Аучыларның атып төшергән үрдәкләрен алырга дип кергән этләрен дә кабып йоткалаган дип язып чыктылар. Ә Шотландиядәге Лох-Несс дип аталган күлдә яшәүче динозавр турында хәзер бөтен дөнья белә.

Башымда берсеннән-берсе шомлырак уйлар туып кына тора. Их, дип уйлыйм мин, бәлки, безгә ишелеп, егылып төшкән урыныбыздан китәргә дә кирәк булмагандыр? Билгеле шулай...

Шундук үз-үземне тынычландыргандай итеп тә карыйм. Кем белә, бәлки, без бая ишеткән тавыш ул кадәр үк хәтәр нәрсә дә түгелдер. Чыннан да, бәлки зуррак ярканат яки тагын берәр шуңар охшашлы җәнлек-фәлән кычкыргандыр?.. Табигатьтә андый хәлләр булгалый бит. Африкадагы ата тәвә кошлар, мәсәлән, җанварлар үкерүенә, аларның калын тавыш белән ырылдавына, хәтта сирәк-мирәк кенә бәргән барабан тавышларына да охшатып кычкыра алалар ди ич.

Ут янында бөрешеп утырам.

Алдан, мәгарәнең без узасы ягыннан, салкынлык бөркелә. Эч пошуга түзәр чама юк. Шулай җылыда үз-үземне кочаклап утыра торгач, калгып киткәнмен. Актүшнең, әкрен генә шыңшып, тезләремә төртелүеннән чәчрәп киттем. Бу Актүшнең йокламаска, сак, уяу булырга кушуыдыр инде, мөгаен.

Шул вакыт ут яктысында Марсиянең күз карашына игътибар иттем. Моңарчы булмаганча җитди карый иде ул. Мәгарәнең түшәменә карап ята. Бу минутта нәрсә турында уйланды икән ул? Баш очыбызда йолдызлар гына да юк бит ичмаса! дип уйлагандыр, мөгаен.

— Нишлибез, Марсия?..— дидем мин, аны әлеге күңелсез уйларыннан арындырырга теләп.

— Китәргә, юлны дәвам итәргә кирәк. Болай булмый...

— Дөрес. Киттек, Марсия!

Булган җылы киемнәребезне киеп, чак кына капкалап алгандай иттек тә яңадан сәфәр чыктык...

Бара торгач, алдыбызда сәер бер яктылыкка чумган искитмәле манзара ачылды. Як-ягыбыздагы ярлар да, баш очыбыздагы гөмбәз дә, шул сәер яктылыкка төренеп, кинәт кенә күздән югалган сыман булды. Бер якта, янар тауларны хәтерләтеп, зәңгәрсу төс бөркеп, киртләч кыялар тезмәсе сузыла. Өстән дә, нәкъ һавадагы иксез-чиксез йолдызлардан төшкән сыман, тонык кына яктылык сирпелә. Менә-менә сул яктагы зәңгәр төстәге янар таулар артыннан, тирә-юньне тагын да яктырта төшеп, тулы ай калкып чыгар кебек иде. Һавасына кадәр үзенчәлекле иде бу мәгарәнең.

Без яр буйлап, сай урыннан читләшмәскә тырышып, тавыш-тынсыз гына алга шуышабыз. Агым бетте. Колгамны суга батырып төпкә терим дә, кулларымны колга буйлап өскә таба күчереп, салны алга таба этәрәм...

Шул чакта, күл урталыгында, су шопырдаган тавыш ишетелде. Ул да булмады, без ишеткән шыксыз аваз яңадан һаваны ярды. Тавыштан бөтен мәгарә эче тетрәп китте. Без югалып, тәмам каушап калдык.

Актүш тә, бичара, елап-чинап өзгәләнә: тыяр хәл юк үзен.

Мин, тиз генә фонаремны кабызып, күл өстен айкый башладым. Су өстеннән иләмсез бер баш калкып чыкты да безнең якка карап тора башлады. Менә кайда икән ул аждаһаның атасы! Чәчләрем үрә торды.

Ул да булмады, аждаһаның, түше белән суны ярып, безгә таба якынлашуын абайлап алдым. Тирә-якка бары тик дулкыннар гына таралып кала.

— Марсия!.. Син дә колгаңны ал!..

Мин кычкырам. Актүш өрә. Марсия дә миңа мөрәҗәгать итеп, нәрсәдер әйтә кебек... Тирә-якта бары тик су шопырдый да дулкыннар шаулаша.

Хәзер инде мин динозаврның башы белән озын муенын гына түгел, сырты-аркасы буенча сузылган киртләч панцирына кадәр аермачык күрәм. Сизелеп тора, каты кабырчыклы, калканлы, көбә тиреле җанвар иде ул.

Кинәт түрдәге янар таулар тезмәсе ягыннан тагын шундый ук аждаһаларның яман үкерешүләре ишетелде. Авызын зур ачып, тешләрен ыржайтып безнең арттан куа килгәне дә, тегеләренә җавап кайтарып, тавыш биреп куйды. Баш очыбызда күк күкрәдемени! Кулымнан колгам төшеп китә язды. Әйе, хәзер инде бернинди

дә шик калмады: динозаврлар өненә килеп эләккәнбез икән!..

Монда инде ике уйлар вакыт юк. Мин тиз генә салны яр буена бордым. Анда — текә таулар тезмәсе. Ярга чыгып, таш арасына яшеренерлек тә түгел бит ичмаса!..

Бәхетебезгә каршы, стена кебек булып торган кыяярда куышлыклар бар икән. Без салыбызны юл өстендә очраган беренче тау куышына юнәлттек... Мәгарә, тәбәнәк булса да, сал сыярлык булып чыкты. Бары тик шунда гына: «Уф-ф!»— дип иркен сулыш алдык. Чөнки арттан эзәрлекләп килүче динозаврның эскерт кадәрле гәүдәсе без кереп качкан тау куышына сыярлык түгел иде.

АЛДА — АФӘТ ГӨРЕЛТЕСЕ

Без килеп кергән тау куышы эчендә агым шактый көчле иде. Безне шул агым суырып алган икән. Аннан тагын да киңрәк җиргә килеп чыктык. Бераздан инде без мул сулы, көчле агымлы шактый зур елгада идек.

Эчкә җан кереп, чак кына тынычланырга да өлгермәдек, алгы яктан тонык гөрелте ишетелә башлады. Безнең сал, ниндидер яман көч ихтыярына буйсынып, гаять зур тизлек белән алга йөзә. Як-ягыбызда чәрдәкләнеп, ишелеп-ярылып беткән ярлар гына чагылып кала.

Агым торган саен көчәя. Бая тонык кына булган гөрелте хәзер инде аермачык ишетелә башлады. Күңелне яңадан кара шом биләп алды. Алда безне ниндидер хәвеф-хәтәр көтәдер сыман.

Тыелгысыз аккан салның йөрешен әкренәйтү нияте белән, колгамны суга тыгам. Аның төбенә җитеп булмый. Хәзер инде бары бер теләк, ул да булса, салны су астыннан калкып чыгып торган ташларга бәрдермәү...

Әйе, шарлавыкка якынлашып килүебезгә шик калмады. Уч иткән кебек, ярга да чыгарлык түгел бит. Як-якта — текә кыялар.

Борылыш сыман бер җирдә сал туп-туры судан чыгып торган бер ташка таба якынлаша башлады. Тиз генә шул якка чыгып, колгамны алга таба суздым.

Максатым — салны ташка бәрдермәү. Бөтен гәүдәм белән ятып, ташка терәлдем. Әмма колга урта бер җиреннән шартлады да сынды. Үзем дә суга очып төшә яздым. Кулыма тиз генә Марсия колгасын алдым.

Як-ягыбыздагы ярлар шәрәләнде. Ишелеп төшкән эрерәк ташлар янында ак күбекләр кайнап тора. Безнең сал, актарылып-бөтерелеп аккан ташкынга эләккән йомычка кебек, томырылып алга ыргыла... Баягы гөрелте хәзер инде күк күкрәгән сыман булып ишетелә.

Шарлавыкка якынлашып килүебезне Марсия дә сизенде. Зур ачылган күзләрендә — шик һәм сагаю. Актүш турында әйткән дә юк. Тынгысызлана, әрле-бирле аяк астыбызда чуала. Үзе өзлексез шыңшый.

Салыбыз шундый тиз ага, су чәчрәүдән учагыбыз да сүнә башлады. Фонарьны кабызырга мәҗбүр булдым.

Шул вакыт сал су астыннан калкып чыгып торган таш өстенә килеп менде, ахрысы, безне шундый чайкады, мәтәлеп төшеп кала яздык. Ул да түгел, салның ике бүрәнәсе аерылып, ташка эләгеп үрә басты. Беттек!..

— Марсия!..— дидем мин, яман хәл буласын төшенеп.— Миңа тотын!

Учак сүнде. Утыннар да, башка әйберләребез дә тарала башлаган салдан коелып төшеп калды.

— Марсия!.. Миңа тотын...— дип кабат кычкырдым.

Марсиянең миңа чытырдап ябышуын, кайнар сулышын һәм бизгәк тоткандагы кебек бөтен тәне калтырануын тоеп калдым.

Ә гөрелте торган саен көчәя, һаман куәтләнә бара. Зур тизлек белән алга ыргылган салыбыз искәрмәстән генә ике таш арасына барып керде. Ансыз да таралырга торган бүрәнәләрнең бер-берсенә бәрелгән тавышлары ишетелеп калды. Һавага чөелеп, суга барып төштек. Кулымдагы фонарь да каядыр очты. Дөм-караңгылыкта Актүшнең үзәк өзгеч тавыш белән чинаганы гына колак төбемдә калды.

Без актарылып аккан ташкын белән бергә каядыр аска таба очып төшеп киттек...

Мин:

— ...Менә алар!..— дигән тавышка айнып, һушыма килдем, күзләремне ачтым.

Безне зур гына көймәгә күтәреп алганнар иде. Ул арада Марсия дә күзен ачты.

Безне мәгарәгә төшеп эзләүләре турында өйгә, Таулыга, вертолет белән очканда гына ишеттек. Араларында «Шерлок Холмс» та булган, ахрысы, безнең ут ягып ятуыбызны да, сал ясап агым белән төшеп китүебезне дә белгәннәр.

Без урман, болыннар өстеннән очабыз. Баш очыбызда кояш. Барысы да һәйбәт. Әмма шушы могҗизалы сәяхәтне бергә кичергән Актүшнең яныбызда булмавы, югалуы гына күңелебезне әрнетә.

Ниһаять, вертолет Таулы поселогы өстендә. Безне каршы алырга җыелган халык, төрле якка таралышып, вертолетка төшеп утырырга урын бирде...

●

ЭЧТӘЛЕГЕ

Без походта 5
Бәла аяк астында 7
Мәңгелек караңгылык эчендә 11
Азык-төлекне барлыйбыз 15
Көтелмәгән «кунаклар» 18
Көнме, төнме? Белмибез 21
Хәрәкәттә бәрәкәт 25
Асылташлар мәгарәсе 28
«Галапагос» утраулары 30
Һөҗүмнән качабыз 34
Динозаврлар өнендә 37
Алда — афәт гөрелтесе 43

Хасанов Махмут Максудович

В ЛОГОВЕ ДИНОЗАВРОВ

Фантастическая повесть

(на татарском языке)

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов*

Художнигы *Т. Хаҗиәхмәтов*

Художество редакторы *Г. Трифонов*

Техник редакторы *Ф. Абдрахманова*

Корректорлары *З. Бикмөхәммәтова, З. Миңнуллина*

ИБ № 1404

Наборга бирелде 10/II-1978 ел. Басарга кул куелды 6/VI-1978 ел. Типография кәгазе № 1, $84\times108^1/_{32}$. Учет. изд. таб. 2,29. Якынча басма таб. 2,52. Тираж 8000. Заказ Х-93. Бәясе 10 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

ҚАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Татарстан китап нәшрияты сезнең өчен 1978 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгара:

Вергазов А. Дулкыннар ни сөйли.
Гатауллин Р. Ирләр булыйк.
Камалов Б. Канат ярганда.
Камалиев Т. Яшьлеккә кайту.
Кашапов Г. Сәмум җиле.
Коллектив. Пионер сәхнәсе.
Мадьяров Н. Утлы кыя.
Маликова М. Егетлеккә бер адым.
Мансуров Ф. Юл читендә көмеш әрем.
Рәхимов Җ. Өлешемә тигән көмешем.
Рәкыйпов Ш. Геройлар үлмиләр.
Тимергалин А. Адашкан йолдыз.
Фәхретдинов Р. Ташлар моңы.
Фатих Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы.
Әхмәт Гадел. Яшьлек уравы.

10 тиен